| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

от «09» ноября 2022 года № 30

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге территориясендә Гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Туембаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 апрелендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге территориясендә Гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә (Туембаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 октябрендәге 26 номерлы, 2018 елның 17 сентябрендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар белән тулыландырырга:

«- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов